# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАР Ы

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Казиле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**“20” ноябрь 2025 ел** **№ 6**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә, 2025 елның 20 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Казиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, 75 яшьтән узган гражданнардан 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Казиле авылы Г.Гафиятуллина урамы)?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 99 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 51 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 48 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Казиле авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2026 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Казиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, 75 яшьтән узган гражданнардан 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Казиле авылы Г.Гафиятуллина урамы)?

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Казиле авылы, Җиңү урамы, 11 йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.